АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2020 № ПР-163-3

г. Казань

Муниципаль районнарның, шәһәр округларының һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең башкарма сәркатибе урынбасары – юридик идарә башлыгы С. Н. Столяров мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет) **карар итте**:

1. Советның башкарма сәркатибе урынбасары – юридик идарә башлыгы С.Н.Столяров муниципаль районнарның, шәһәр округларының һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Советка җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү системасын камилләштерү, шул исәптән нәтиҗәлелек күрсәткечләренең гамәлдәге исемлеген үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертергә тәкъдим итәргә.

Вакыты: 2020 елның 2 апреленә кадәр

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының ДБУ "Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге" белән берлектә гамәлдәге күрсәткечләрнең стимуллаштыру йогынтысын арттыру, аларның санын киметү

мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карау турында мөрәҗәгать җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең социаль-икътисадый үсеше дәрәҗәсен бәяләгәндә Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булмаган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары башлыклары һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының ДБУ "Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге" тарафыннан эшләнгән методик тәкъдимнәрне кулланырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

Рәис **Ә.С.Гобәйдуллин**